**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**15.10.2018** **№ 2230**

**Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 22 гыйнварындагы 503 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Яшьләр белән эшләү буенча Иҗтимагый координация Советы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 22 гыйнварындагы 503 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы яшьләр белән эшләү буенча Иҗтимагый координация Советы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-яшьләр проблемаларын хәл итүгә, яшьләрнең социаль инициативаларын алга этәрүгә, шулай ук Биектау муниципаль районын социаль-икътисадый үстерү программасына кагылышлы Россия Федерациясе дәүләт программаларын, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыруда яшьләрнең катнашуы өчен шартлар тудыру;»;

1.2. 4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Яшьләр координация Советы әгъзалары булып, түбәндәгеләр тора алмый:

- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар һәм муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар;

- суд карары нигезендә хокукка сәләтсез дип танылган затлар;

- юкка чыгарылмаган яисә кире алынмаган хөкем ителүе булган затлар;

- икеләтә гражданлыгы булган затлар.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http//vysokaya-gora/tatarstan.ru веб-адрес адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Сабирҗанов